**Межрегиональные предметные олимпиады КФУ**
**профиль «Татарский язык»**
**Заключительный этап**
**ОТВЕТЫ**
**2022-2023 учебный год**
**10 класс**

**I. Һәр тотрыклы гыйбарәне синоним булырдай бер сыйфат белән алыштырып языгыз.** / Запишите каждый фразеологический оборот одним синонимичным прилагательным. (*10 баллов. За каждый правильный вариант по 1 баллу*).
1) Ике башлы – кыю, йөрәкле, чая, җитез, булдыклы, гаярь, гайрәтле, базымлы, курыкмас, каушамас, үткен, үткер, батыр
2) тел бистәсе – лыгырдык, лыбырдык, лыгырдавык, лыкылдык, такылдык, такылдавык, татылдык, татылдавык, тәкелдәвек, тәкелдек, шыбыртык, шалтыравык
3) калай этәч – мактанчык, масаючан, шапырынучан, шапырындык, шапылдык, кукыраючан, эре, һавалы, кыланчык, кылтым, кылтык, кылтаючан
4) акылга сыймаслык – мәгънәсез, юньсез, тозсыз
5) кара эчле – мәкерле, хәйләкәр, хәйләле, эчкерле, хыянәтле, хыянәтчел, кинәчел, эчле
6) авыр сөякле – мыштыр, авыр, әкрен, мыштырдык, сүлпән, мыштым
7) каты күңелле – рәхимсех, мәрхәмәтсез, шәфкатьсез, аяусыз, кешелексез, миһербансыз, кызганмаучан, җансыз, залим,усал, явыз, кызганусыз, кансыз
8) колакка каты – саңгырау, чукрак,
9) туймас күз – комсыз, карун, каудар, кысмыр,саран
10) кулыннан килә – сәләтле, булдыклы, булган, талантлы, башлы, зирәк

**II.** ***Мәл – ләм, кесә – сәке, ташы – шыта*** **мисалларында тел уйнату нәрсәгә нигезләнгән? Ул кайсы термин белән атала? Әлеге алымны кулланып,** ***алда, буа, идарә, табак*** **сүзләренең парларын языгыз. Шундый ук тагын 2 мисал китерегез.** / На чём основана языковая игра в примерах *мәл – ләм, кесә – сәке, ташы – шыта*? Каким термином она обозначается? Используя данный приём, запишите соответствующую пару для каждого слова: *алда, буа, идарә, табак*. Приведите 2 аналогичных примера. (*10 баллов. 1 балл за объяснение сути приёма языковой игры; 1 балл за правильно указанный термин; по 1 баллу за каждое верно разгаданное слово и за объяснение значения; по 2 балла за каждый свой пример*).
1) Тел уйнату, сүз эчендәге хәрефләрнең урынын үзгәртеп, яңа сүз ясауга нигезләнгән.
2) Бу алым анаграмма дип атала.
3) **алда - дала**
**Буа - уба**
**Идарә - даирә**
**Табак - кабат**
4) Шат – таш
Бөтен – төбен

**III. Җөмләнең һәр сүзенә морфологик анализ ясап языгыз. /** Сделайте морфологический анализ каждого слова в этом предложении (10 баллов).

*Яхшылык эшләү хисе һәр кешенең күңелендә дөньяга килгән көненнән яши.*
**Яхшылык** – исем, уртаклык исем, ясалма исем, берлек санда, тартым белән төрләнмәгән, баш килештә, җөмләдә тәмамлык
**Эшләү** – фигыль, исем фигыль, затланышсыз, барлыкта, баш килештә, җөмләдә аергыч.
**Хисе** – исем, уртаклык исем, тамыр исем, берлек санда, III зат тартым белән төрләнгән, баш килештә, җөмләдә ия

**Һәр** – алмашлык, билгеләү алмашлыгы, тамыр алмашлык, аергыч
**Кешенең** – исем, уртаклык исем, тамыр исем, берлек санда, тартым белән төрләнмәгән, иялек килешендә, җөмләдә аергыч
**Күңелендә** – исем, уртаклык исем, тамыр исем, берлек санда, III зат тартым белән төрләнгән, урын-вакыт килешендә, җөмләдә хәл
**Дөньяга** – исем, уртаклык исем, тамыр исем, берлек санда, тартым белән төрләнмәгән, урын-юнәлеш килешендә, җөмләдә хәл
**Килгән** – сыйфат фигыль, тамыр нигез, төп юнәлештә, барлык формасында, үткән заманда, җөмләдә аергыч.
**Көненн**ән – исем, уртаклык исем, тамыр исем, берлек санда, III зат тартым белән төрләнгән, чыгыш килешендә, җөмләдә хәл
**Яши** – фигыль, хикәя фигыль, тамыр фигыль, хәзерге заманда, 3 затта, берлек санда, барлыкта, җөмләдә хәбәр.

**IV. Лингвистик терминнар һәм тел берәмлекләре арасында тәңгәллекләр урнаштырыгыз. Җавапны сан – хәреф формасында языгыз.** / Установите соответствие между лингвистическими терминами и языковыми единицами. Ответ представьте в виде: цифра - буква. (10 баллов. *За каждый правильный вариант по 1 баллу* )
1) Паронимнар; 2) синонимнар; 3) тарихи сүзләр; 4) архаизмнар; 5) омонимнар; 6) диалектизмнар; 7) алынма сүзләр; 8) антонимнар; 9) Күп мәгънәле сүзләр; 10) Бер мәгънәле сүзләр.
А) Морза, ясак; Ә) Алма, каралу; Б) Мүк, дөя; В) Олы, өлкән; Г) Чирек, сабак; Д) Инәй, наный; Е) Тирбәтә – тибрәтә, игелек – изгелек; Ж) Язмак, кеби; З) Ялгыз, күмәк; И) Гыйлем, өстәл;

**1 – Е; 2 – В; 3 – А; 4 – Ж; 5 – Ә; 6 – Д; 7 – И; 8 – З; 9 – Г; 10 – Б**

**V. Русча гыйбарәләрнең татарча эквивалентларын языгыз.** / Напишите татарские эквиваленты, соответствующие выражениям на русском языке. (15 баллов. *За каждый правильный вариант по 3 балла*)
**Ломовая лошадь** – эш аты, йөк аты
**Бездонная бочка** – төпсез мичкә, төпсез кисмәк
**Краем уха** – колак чите белән
**Дурной глаз** – яман күз
**Голова садовая** – ачык авыз, мәми авыз

**VI. Тамырының мәгънәсе белән сүзләрнең берсе башкаларыннан аерылып тора. Әлеге сүзне табыгыз һәм мәгънәсен языгыз. Шул тамырдан 2 яңа сүз уйлап языгыз.** / Одно из слов отличается от других значением корня. Запишите это слово и смысл. Из этого корня придумайте 2 новых слова. (*5 баллов. 3 балла за правильно указанное слово и смысл; по 1 баллу за каждое верно написанное слово*)
Очсыз, очучы, очлау, очлы, очлык

**очучы** – очкычлар белән идарә итүче.
Очкыч, очындыру һ.б.

**VII. Татар теленең авазлары турында ниләр беләсез? 1) сузык авазлар һәм 2) тартык авазлар, 3) аваз үзгәрешләре турында языгыз; һәрберсенә мисаллар китерегез.** / Что Вы знаете о звуках в татарском языке? Напишите о 1) гласных звуках; 2) согласных звуках; 3) звуковых изменениях; приведите примеры. *(15 баллов. Каждый критерий оценивается 5 баллами)*

Аваз – сөйләмнең таркалмый торган иң кечкенә берәмлеге.
Хәзерге татар телендә 12 сузык, 28 тартык аваз бар:
Авазлар сузыкларга һәм тартыкларга бүленәләр. Сузыклар һәм тартыклар арасында өч аерма бар:
артикуляцион аерма: сузыкларны әйткәндә, үпкәдән килә торган һава агымы тоткарлыксыз үтә; тартыкларны әйткәндә, сөйләм аппаратының берәр урынында каршылыкка очрый, һава агымы көчлерәк тә була.
акустик аерма: сузыклар тавыштан, гармоник һава тирбәнешләреннән торалар, тартыкларны әйткәндә шау да катнаша.
лингвистик аерма: сузыклар иҗек ясаучы авазлар, тартыклар үзләре генә иҗек ясый алмыйлар.
Татар телендә барлыгы 12 **сузык аваз** кулланыла.
Шуларның 9-ы татар теленең үз сузыклары : [а][ә][о][ө][у][ү][ы][и][э]
3 сузык аваз рус теленнән кергән, алар - [о][ы][э]
Әйтү үзенчәлеге буенча сузык авазларны калын һәм нечкә сузыкларга бүләләр.
Калын сузыкларны икенче төрле арткы рәт сузыклар дип атыйлар.
Нечкә сузыкларны исә алгы рәт сузыклар дип атыйлар.
Арткы рәт сузыклар: [а][о][у][ы][о][ы]
Алгы рәт сузыклар: [ә][ө][ү][и][э][э]
Иренләшкән сузык авазлар: [о] [ө] [у] [ү] [о]
Иренләшмәгән сузыклар: [а] [ә] [ы] [и] [э] [ы] [э]
Парлы сузыклар:
[а] - [ә]
[о] - [ө]
[у] - [ү]
[ы] - [э]
Бер иҗектә 2 сузык авазның янәшә килүе дифтонг дип атала.
Татар теленең дифтонглары - ау/әү, яу/яү. Мәсәлән: бау, дәү, буяу, кияү.
Сүзләрне төрләндергәндә, дифтонгларның составы үзгәрә: алар ике иҗеккә бүленәләр, язуда у, ү хәрефләре урынына в хәрефе кулланыла: олау - олавы, яу - явы.
Сингармонизм законы. I төре
Сузыкларның нечкәлектә-калынлыкта ярашуы сингармонизм законының I төре дип атала.
Мәсәлән: урманчы сүзендә [у],[а],[ы] кебек калын сузыклар гармониясе күзәтелә, ә бөркәнчек сүзендә исә [ө][ә][э] нечкә сузыкларын ишетәбез.
Законның әлеге төре икенче төрле рәт гармониясе дип атала.
II төре
Сүзнең беренче иҗегендә о,ө хәрефе булып, икенчә иҗектә ы,э хәрефләре килсә, беренче иҗектәге [о],[ө] авазлары тәэсирендә икенче иҗектә дә шул ук [о],[ө] авазларын ишетәбез, әйтәбез.
Мәсәлән: бөре – [б][ө][р][ө], тозлы – [т][о][з][л][о].
Законның бу төре икенче төрле ирен гармониясе дип тала.
Аваз ясалганда тавыш ярыларының катнашуыннан чыгып, **тартык авазлар** саңгырау: [п], [т], [с], [х], [ш], [ч], [к], [к], [ф], [х], [һ], [ц], [щ], [тч], ['] – «һәмзә» һәм яңгырау: [б], [в], [w], [ж], [ж], [г], [ғ], [р], [м], [н], [ң], [л], [й], [д], [з] – тартыкларга бүлеп каралалар.
Шау ясаучы киртәнең характерыннан чыгып, тартык авазлар йомык, ярымйомык һәм йомык-үтешле төрләргә бүленәләр.
Йомык тартыклар ясалганда, ике актив сөйләм органы – аскы һәм өске иреннәр яки актив орган белән пассив орган, мәсәлән, тел белән аңкау бер-берсенә якын килеп йомылалар. Һава агымы ул йомыклыкны я әйләнеп үтәргә, яисә шартлап чыгып китәргә тиеш була.
Сөйләмдә авазлар бер-берсенә ялганып, тоташ агым булып баралар. Шуңа күрә **авазларда төрле үзгәрешләр була**. Бу үзгәрешләрне, ни сәбәпле булуларыннан чыгып, ике төргә бүләләр: комбинатор һәм позицион үзгәрешләр.

Аккомодация – төрле характердагы авазларның бер-берсенә җайлашуы, сузыкларның тартыкларга, тартыкларның сузыкларга тәэсире нәтиҗәсендә барлыкка килә торган аваз үзгәрешләре.
Артикуляция – сөйләм органнарының нинди дә булса авазны әйткәндәге эшчәнлеге. Ул өч этаптан тора: экскурсия (авазны әйтүгә хәзерлек моменты), тукталыш (авазны әйтү), рекурсия (сөйләм органнарының яңадан үз хәленә кайтуы)
Ассимиляция – авазларның әйтелеш һәм яңгыраш ягыннан бер- берсенә охшашлануы.
Диссимиляция – авазларның охшашсызлануы. Авыр әйтелешле бертөрле авазларның берсен җиңелрәк әйтелешле икенче бер аваз белән алыштыру. Күбрәк гади сөйләмдә, алынма сүзләрнең әйтелешендә чагылыш таба.
Комбинатор аваз үзгәрешләре – төрле комбинацияләрдә килгәндә, авазларның бер-берсенә тәэсир итешү нәтиҗәсендә барлыкка килә торган аваз үзгәрешләре (ассимиляция, аккомодация, диссимиляция).
Метатеза – ассимиляция яки диссимиляция нәтиҗәсендә авазларның, иҗекләрнең урыннары алышыну (азбар-абзар).
Редукция – басымсыз позициядә сузык авазларның үзгәрүе.
Сандхи – җөмләдә рәттән әйтелгән сүзләрнең алдагысы сузык авазга тәмамланып, аның артыннан килгәне дә сузык авазга башланса һәм әлеге сүзләр пауза белән бүленмичә, бер синтагма тәшкил итсәләр, чиктәш сузыклар бер-берсенә тоташып, берегеп әйтеләләр.
Саңгыраулашу – сүз азагында яки саңгырау тартыклар алдында килгәндә, кайбер яңгырау тартыкларның саңгырау парлары белән чиратлашулары (тозсыз [тоссос]).
Сингармонизм – сүз эчендә сузык авазларның рәт һәм иренләшү ягыннан ярашып, охшашланып килүе, сузыклар гармониясе.
Сингармоник парлар (сингармоник параллельләр) – этимологик яктан бер үк тамырга караган һәм бары тик рәт гармониясе буенча гына аерыла торган сүзләр.

**Сузыкларның кыскаруы**

Кайбер сүзләрдә басымсыз иҗекләрдә килгән [ы][э] сузык авазлары мускул киеренкелеге киму нәтиҗәсендә йотылалар яки әйтелмиләр.
Әлеге күренеш сузыкларның кыскаруы, фәнни телдә редукция дип атала.
Мәсәлән: сеңелем – [сэңлэм], авыру - [ awру ]
Алынмалардагы сузыкларның үзгәреше
Рус теле аша кергән сүзләрдә басымлы иҗек алдыннан килгән [о] авазы [а]авазы булып әйтелә. Мәсәлән: портрет, корсет.
Рус теле аша кергән сүзләрдә басымлы иҗектән соң килгән [о] авазы [ы]авазы булып әйтелә. Мәсәлән: архитектор, директор.

**VIII«Безнең халыкны гасырлар буена китап тәрбияләп, ышаныч һәм өмет биреп, киләчәккә алып барган һәм тарих упкынына төшеп югалудан саклап калган» дип язган Разил Вәлиев. Сез ничек уйлыйсыз? Шуңа мөнәсәбәтегезне белдереп языгыз. Язмагыз 80 сүздән ким булмаска тиеш. Фикерегезне дәлилләп, 2 дән ким булмаган дәлил китерегез.** / «Книга веками воспитывала, доверчиво и с надеждой провожала наш народ в будущее и уберегла от исчезновения в пропасти истории», - пишет Разиль Валиев. Как Вы думаете? Напишите сочинение-рассуждение (не менее 80 слов), выражая ваше отношение к этому. Приведите не менее 2 довода-примера (20 баллов)

| № | Сочинениене бәяләү критерийлары | Баллар |
|---|---|---|
| ***I*** | ***Иншаның эчтәлеге*** | |
| | Язманың эчтәлеге темага туры килә. Эчтәлеге тулысынча ачылган. Икедән артык дәлил бирелгән. | 4 |
| | Язманың эчтәлеге, нигездә, темага туры килә. Эчтәлеге ачылган. 1-2 гомуми дәлил бар. | 3 |

| | | |
|---|---|---|
| | Язманың эчтәлеген бирүдә җитди ялгышлар бар. 1 дәлил бар. | 2 |
| | Язманың эчтәлеге ачылмаган<br>**яки**<br>мисал буларак дәлил  язылмаган. | 0 |
| ***II*** | ***Иншаның тел ягы*** | |
| | **Язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге, язу эзлеклелеге** | |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана:<br>– логик хаталар юк, язуда эзлеклелек бозылмаган;<br>– абзацларга бүленештә хаталар юк. | 2 |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана,<br>**ләкин**<br>1 логик хатасы бар,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **1** урында хата бар. | 1 |
| | Язмада сөйләм үстерүгә омтылыш бар,<br>**ләкин**<br>логик хаталарның саны 1 дән артык,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **2** урында хата бар. | 0 |
| | **Төгәллек һәм сөйләм матурлыгы** | |
| | Язмада фикер төгәл, төрле грамматик формалар кулланылган. | 2 |
| | Язмада фикер төгәл,<br>**Ләкин** бер генә төрле сөйләм калыпларыннан файдаланылган,<br>**яки**<br>язмада төрле грамматик формалар кулланылган,<br>**ләкин** фикер төгәллеге бозылган. | 1 |
| | Сүз байлыгыннан тиешенчә файдалана алмаган, бер үк төрле җөмлә калыпларын гына кулланган. | 0 |
| ***III*** | ***Грамоталылык*** | |
| | **Орфографик нормаларның үтәлеше** | |
| | Орфографик хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | Хатасы 2 дән артык түгел. | 2 |
| | 3-4 хата җибәрелгән | 1 |
| | Хаталарының саны 4 тән артык | 0 |
| | **Пунктуацион нормаларның үтәлеше** | |
| | Пунктуацион хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | 1-3 хатасы бар. | 2 |
| | 4-5 хатасы бар. | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| | **Тел нормаларының үтәлеше** | |
| | Грамматик хаталары юк | 2 |
| | 1–2 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 2 дән артык | 0 |
| | **Сөйләм нормаларының үтәлеше** | |
| | Сөйләмгә кагылышлы 1 генә хатасы бар | 2 |
| | **2–3** хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны **3** тән артык | 0 |
| | **Этикага кагылышлы нормаларның үтәлеше** | |

| | | |
|---|---|---|
| | Этикага кагылышлы хаталары юк | 1 |
| | Хаталары бар (1 һәм 1дән күбрәк) | 0 |
| | **Язмада фактларны бирүдәге төгәллекнең үтәлеше** | |
| | Фактик хаталары юк. | 1 |
| | Фактик хаталары бар. | 0 |
| **Язма эш өчен максималь балл** | | **20** |